КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.07.2026 Казан шәһәре № 471-П

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү, территориясе чикләрен һәм аннан файдалануның махсус режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Әлеге боерыкның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертергә.

2. Расларга:

әлеге боерыкка 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләрен;

әлеге боерыкка 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның махсус режимын;

3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсе мәдәни катламы» мәдәни (археологик) мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү турында»

2025 елның 4 декабрендәге 783-П номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.


Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
28 июлендәге 471-П номерлы
боерыгына 1 нче кушымта

АЧЫКЛАНГАН МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕНӘ КЕРТЕЛГӘН АРХЕОЛОГИК МИРАС ОБЪЕКТЫ

| | |
|---|---|
| Объектның исеме | XVIII-XIX гасырларда Архангел бистәсенең мәдәни катламы. |
| Урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Вахитов районы, Һади Такташ ур. Һәйкәл Түбән Кабан күленең уң ярында урнашкан, кадастр номерлары 16:50:011412:12, 16:50:011412:537 булган җир кишәрлекләре |
| Датировкасы: | XVIII-XIX гасырлар. |

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының урнашу урынының вәзгыяти планы





- объектның урнашу урыны

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
28 июлендәге 471-П номерлы
боерыгына 2 нче кушымта


Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)



территория чикләренең характерлы ноктасы

изолинияләр



бина

объект территориясе чиге

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

| Нокта № | Җирле координаталар системасында нокта координаталары (МСК-16, зонаl) | | 1984 елгы Бөтендөнья геодезия координаталар системасында координаталар (WGS-84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | У | N | E |
| 1 | 474246,34 | 1306059,75 | 55.77557185 | 49.12831496 |
| 2 | 474248,53 | 1306059,93 | 55.77559143 | 49.12831787 |
| 3 | 474247,32 | 1306071,88 | 55.77558041 | 49.12850828 |
| 4 | 474255,49 | 1306072,81 | 55.77565378 | 49.12852327 |
| 5 | 474257,38 | 1306060,68 | 55.77567091 | 49.12833002 |
| 6 | 474264,09 | 1306061,24 | 55.77573126 | 49.12833909 |
| 7 | 474264,13 | 1306060,91 | 55.77573153 | 49.12833383 |
| 8 | 474306,83 | 1306064,66 | 55.77611501 | 49.12839452 |
| 9 | 474306,97 | 1306063,08 | 55.77611628 | 49.12836935 |
| 10 | 474327,07 | 1306065,60 | 55.77629679 | 49.12840994 |
| ll | 474327,32 | 1306066,36 | 55.77629902 | 49.12842206 |
| 12 | 474325,17 | 1306086,82 | 55.77627946 | 49.12874806 |
| 13 | 474323,85 | 1306093,71 | 55.77626752 | 49.12885782 |
| 14 | 474318,60 | 1306092,68 | 55.77622038 | 49.12884130 |
| 15 | 474318,07 | 1306095,69 | 55.77621558 | 49.12888925 |
| 16 | 474314,86 | 1306110,45 | 55.77618656 | 49.12912439 |
| 17 | 474308,20 | 1306106,39 | 55.77612680 | 49.12905954 |
| 18 | 474302,37 | 1306103,06 | 55.77607447 | 49.12900635 |
| 19 | 474301,47 | 1306110,80 | 55.77606630 | 49.12912967 |
| 20 | 474280,98 | 1306106,69 | 55.77588231 | 49.12906373 |
| 21 | 474275,97 | 1306101,19 | 55.77583738 | 49.12897597 |
| 22 | 474259,90 | 1306098,47 | 55.77569308 | 49.12893227 |
| 23 | 474260,04 | 1306097,26 | 55.77569444 | 49.12891300 |
| 24 | 474240,40 | 1306095,13 | 55.77551806 | 49.12887862 |
| 1 | 474246,34 | 1306059,75 | 55.77557185 | 49.12831496 |

# Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләренең текстлы тасвирламасы

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясе чикләре линиясе түбәндәгечә уза:

| Чик өлешләре турында белешмәләр | | |
|---|---|---|
| Чик өлешен билгеләү | | Чикләрне узуның тасвирламасы |
| Ноктадан | Ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | төньякка таба (азимут 5º) 2,18 метр |
| 2 | 3 | көнчыгышка таба (азимут 96º) 12,01 метр |
| 3 | 4 | төньякка таба (азимут 6º) 8,22 метр |
| 4 | 5 | көнбатышка таба (азимут 279º) 12,3 метр |
| 5 | 6 | төньякка таба (азимут 5º) 6,74 метр |
| 6 | 7 | көнбатышка таба (азимут 279º) 0,33 метр |
| 7 | 8 | төньякка таба (азимут 279º) 20,26 метр |
| 8 | 9 | көнбатышка таба (азимут 279º) 1,59 метр |
| 9 | 10 | көнчыгышка таба (азимут 279º) 0,80 метр |
| 10 | 11 | көнчыгышка таба (азимут 72º) 0,80 метр |
| 11 | 12 | көнчыгышка таба (азимут 96º) 20,57 метр |
| 12 | 13 | көнчыгышка таба (азимут 101º) 7,01 метр |
| 13 | 14 | көньякка таба (азимут 191°) 5,35 метр |
| 14 | 15 | көнчыгышка таба (азимут 100°) 3,05 метр |
| 15 | 16 | көнчыгышка таба (азимут 102º) 15,10 метр |
| 16 | 17 | көньякка таба (азимут 211º) 7,80 метр |
| 17 | 18 | көньякка таба (азимут 211º) 6,71 метр |
| 18 | 19 | көнчыгышка таба (азимут 97º) 7,72 метр |
| 19 | 20 | көньякка таба (азимут 191°) 20,90 метр |
| 20 | 21 | көньякка таба (азимут 228º) 7,44 метр |
| 21 | 22 | көньякка таба (азимут 190°) 16,3 метр |
| 22 | 23 | көнбатышка таба (азимут 277º) 1,22 метр |
| 23 | 24 | көньякка таба (азимут 186º) 19,75 метр |
| 24 | 1 | көнбатышка таба (азимут 280º) 35,87 метр |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
28 июлендәге 471-П номерлы
боерыгына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә урнашкан «XVIII-XIX гасырлар Архангел бистәсенең мәдәни катламы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның махсус режимы

Чикләрендә археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) билгеләнгән тәртиптә 73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында билгеләнгән археологик кыр эшләрен, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның аннан файдалана алуын тәэмин итү шарты белән башка эшләрне уздыру мөмкинлеген күздә тота.

1. Рөхсәт ителә:

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы биргән рөхсәт (ачык кәгазь) нигезендә археологик мирас объектын өйрәнү эшләрен, археологик әйберләрне эзләү һәм алу максатын күздә тоткан эшләрне дә кертеп, үткәрү;

мондый эшләрне башкару проектларында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планында археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашыру шарты белән, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм башка эшләрне башкару;

законнар нигезендә гражданнарның археологик мирас объектына керүләрен оештыру;

2. Тыела:

мондый эшләрне башкару проектларында яисә археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү проектларында яки уздырыла торган эшләрнең археологик мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен уздыру планында археологик мирас объектыныңсаклап калу, файдалану, популярлаштыру өлкәсендә вәкаләтле орган белән сакланышын тәэмин итү турында, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән мәҗбүри бүлекләрне гамәлгә ашырмыйча, ачыкланган археологик мирас объекты территориясе чикләрендә урманнардан файдалану буенча 73-ФЗ номерлы федераль

законның 30 статьясында күрсәтелгән эзләнү, проект, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен һәм башка эшләрне башкару.